**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

---

2020елның 3ноябре 16 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Түбән Кармачы торак пункты гражданнары җыенының карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Александровка торак пункты гражданнары җыены карар кабул итте**:**

1. Лаеш муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Түбән Кармачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда үзара салым чараларын 500 сум күләмендә кертергә, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидлар керми.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә.:

- Түбән Кармачы торак пунктында контейнер мәйданчыгы төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
- Түбән Кармачы торак пунктында җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү);.

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ________________ **И.А.Бандурова**

Александровка авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ________________ **И.А.Бандурова**